САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№22 17.12.2015

№ ____ _______

# КАРАР

2016 елга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының бюджеты турында

Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе Сөнгатов Ш.А. докладын тыңлаганнан соң, Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ :

2016 елга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Саба муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 882 566,470 мең сум күләмендә;

2) Саба муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 882 566,470 мең сум күләмендә;

3) Саба муниципаль районы бюджеты кытлыгын 0,000 мең сум күләмендә.

2. 2016 елга Саба муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

3. 2017 елның 1 гыйнварына Саба муниципаль районының муниципаль эчке бурычының югары чиге 0,000 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча бурычның югары чиге 0,000 мең сум күләмендә расларга.

4. 2016 елга Саба муниципаль районының муниципаль бурычының чик күләмен 0,000 мең сум күләмендә билгеләргә.

5. Саба муниципаль районы бюджетында 2016 елга Саба муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

6. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 184.1 статьясындагы 2 пункты нигезендә 2016 елга Саба муниципаль районы бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативларын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

7. 2016 елда Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетына 2015 ел йомгаклары буенча салымнарны түләгәннән һәм башка мәҗбүри түләүләрне башкарганнан соң калган Саба муниципаль районының

муниципаль унитар предприятиеләре табышының бер өлеше 2016 елның 1 июленә кадәр чиста табышның 30 проценты күләмендә кертелә дип билгеләргә.

8. Саба муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

9. Саба муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

10. 2016 елга Саба муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

11. Саба муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2016 елга бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Саба муниципаль районының муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә расларга.

12. Саба муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2016 елга бюджет чыгымнары классификациясенең максатчан статьяларына (Саба муниципаль районының муниципаль программаларына һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләренә), чыгымнар төрләре төркемнәренә, бүлекләренә, бүлекчәләренә, бүлекчәләренә бүлүне әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә расларга.

13. 2016 елга Саба муниципаль районы бюджетының гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 14 107,200 мең сум күләмендә расларга.

14. 2016 елга җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр бүлүне әлеге карарга 9 нчы кушымта нигезендә 24 907,300 мең сум итеп расларга.

15. Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күләмен 2016 елга 1 507,200 мең сум әлеге карарга 10 нчы кушымта нигезендә расларга.

16. 2016 елга граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күләмен 67,048 мең сум әлеге карарга 11 нче кушымта нигезендә расларга.

17. Саба муниципаль районы бюджетында 2016 елга Татарстан Республикасы бюджетыннан 392 877,000 мең сум күләмендә алына торган субсидияләр күләмен исәпкә алырга, шул исәптән:

- бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә субсидияләр һәм муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү 23 985,800 мең сум күләмендә;

- муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә,

башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыруга һәм бирүгә, муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыруга, балаларны карап тәрбияләү һәм тәрбияләү өчен шартлар тудыруга, шулай ук каникул вакытында балаларның ялын оештыруга 368 891,200 мең сум күләмендә шартлар тудыруга субсидияләр.

18. Саба муниципаль районы бюджетында 2016 елга Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр күләме 230 900,470 мең сум күләмендә исәпкә алынды, шул исәптән:

- җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан җирлекләргә 921,500 мең сум күләмендә дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр;

- муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне 159 389,000 мең сум күләмендә тәэмин итүгә субвенцияләр;

- муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә 59 624,300 мең сум күләмендә субвенцияләр;

- мәгариф өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга 255,700 мең сум күләмендә субвенцияләр;

- белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга 4 192,700 мең сум күләмендә субвенцияләр;

- балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга 506,500 мең сум күләмендә субвенцияләр;

- административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга 245,000 мең сум күләмендә субвенцияләр;

- дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга 255,700 мең сум күләмендә субвенцияләр;

- архив эше өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга 42,900 мең сум күләмендә субвенцияләр;

- опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга 716,400 мең сум күләмендә субвенцияләр;

- административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга 0,370 мең сум күләмендә субвенцияләр;

- хайваннар авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, халыкны кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр 1 853,400 мең сум күләмендә, шул исәптән 1 797,000 мең сум күләмендә

түләнгән терлек каберлекләрен һәм биотермик чокырларны тотуга, күзәтүчесез хайваннарның санын көтүгә, тотуга һәм җайга салуга 56,400 мең сум күләмендә субвенцияләр;

- йогышлы авырулар чыганакларында, шулай ук йогышлы авырулар барлыкка килү яисә таралу өчен шартлар булган һәм сакланган территорияләрдә һәм урыннарда дезинфекция, дезинсекция һәм дератизация үткәрү чараларын, санитар-эпидемиягә каршы (профилактик) чараларны үткәрүне оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр;

- хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга 1 507,200 мең сум күләмендә субвенцияләр;

- гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга 955,200 мең сум күләмендә субвенцияләр;

- Россия Федерациясендә гомуми юрисдикциядәге федераль судларның присяжный утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (үзгәртү) буенча субвенцияләр 14,600 мең сум күләмендә;

- муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүматны җыю вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр 2,000 мең сум күләмендә;

19. 2016 елга муниципаль районнарның бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә региональ финанс ярдәме фондыннан 197 944,800 мең сум күләмендә, шул исәптән, 0,000 мең сум күләмендә акчалата чагылышта, аларны физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативларын 197 944,800 мең сум күләмендә алмаштыручы дотацияләрне исәпкә алу.

20. 2016 елга Саба муниципаль районы Юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 8 972,000 мең сум күләмендә расларга һәм аларны ремонтның муниципаль программасын гамәлгә ашыруга һәм 2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын норматив хәлгә китерү өчен җибәрергә.

21.Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнары 2016 елда муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар, шулай ук яңа кертелә торган объектлар саныннан тыш, аларны тотуга чыгымнар кабул итәргә хокуксыз.

Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына 2016 елда җирлекләрнең муниципаль хезмәткәрләре һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарларны кабул итмәскә киңәш итәргә.

22. Саба муниципаль районы бюджетының калган акчалары - Саба муниципаль районы исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар өчен 2015 елда шушы муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланылмаган

бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә, 2016 елда, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

23. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Саба районы буенча Казначылык департаментының территориаль бүлеге төзелгән килешүләр нигезендә Саба муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләр башкара.

24. Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

25. Әлеге карарны «Саба таннары» район газетасында һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов